Республика Татарстан
**СОВЕТ ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Ахмадиева, д.26, п. Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК СОВЕТЫ**

Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы,423368
Телефон: (85559) 31-0-97,60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

**РЕШЕНИЕ**
24.11.2021 ел

**КАРАР**
№ 59

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне яңа редакциядә раслау хакында» Сарман районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242_17 статьясындагы 4 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2021 елның 1 июлендәге 244-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 12 маендагы 175 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 9 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өчен физик һәм юридик затлар тарафыннан акчалар түләү өчен кирәкле мәгълүматны, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәрен формалаштыру чыганаклары булган башка түләүләрне «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасына тапшыра, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;»

2) 5 статьяның 10 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) җирлек бюджеты дефицитын финанслау чыганакларын түләү өчен бүлеп бирелгән ассигнованиеләрне кулланунының, бюджетның бердәм счетындагы калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән тыш, адреслылыгын һәм максатчан характерын тәэмин итә»;

3) 5 статьяның 11 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) җирлек бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының бюджетка керүнең тулылыгын һәм үз вакытында керүен, бюджетның бердәм счетында калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән тыш, контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;»

2. Әлеге карарны Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (https://sarmanovo.tatarstan.ru/index.htm) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе Р. Ә. Кәримов